***МИССИОНЕРСКИЙ ЛИСТОК***
***КРЯШЕНСКАЯ ДУХОВНАЯ МИССИЯ (http://www.missiakryashen.ru)***

# АЛЛА ЗАКОНЫНЫҤ УН БОЙОРОГО

**I. Мин Ӱзем сиңа Алла Ходай, Миннян башка сиңа бютян алла булмасын** (*бу беренче бойорокка карышы киля: Православный деннян бизеуче, кюремчелек итеӱгя, гороскопларга ышаныучы, ӱз байлыгына ышаныучы).*

**II. Жугары кюктя, тюбян жирдя, жир астындагы сыуларда да ней нястя бар, ич берсеня дя ошатыб сын жасама, аларга табынма** *(кюб ашауны жаратыучы, эчкелеккя, малга биренеӱче, ӱзеня дан эзляӱче кеше дя сынга табыныучы була. Андый кешелярнен сыннары: корсак, байлык белян дан).*

**III. Алла Ходайынңнын исемен ней життегя телеңя алма** *(Алланы, Христос денен жаманнаб сöйляӱче, чиркяӱне, качны, тярелярне хурлаучы, иткян антын бозоучы, Аллага адарынганын бирмей калыучы, кирякмяскя Алла исемен телгя алыб, кадерсез итеӱче, шул бу бойорокка карышы жазыклы була).*

**IV. Атна кöннö келяӱ кöнö итяргя онотма; алты кöннö бар эшляреңне эшля, жиденчесе атна кöн Алла Ходайыҥ öчöн булсын** (*Бу бойорок атна кöннö, бяйрям кöннö Алланы даннарга, ололарга, аңар инялярга куша. Кара эшне, гадятчя эшне атна кöннö эшлярга кушмый).*

**V. Атаңны, анаңны саннаб тор, ӱзеңя жакшы булыр, жирдя гумереҥ озон булыр.**

**VI. Кеше ӱтермя** *(бу бойорокка карышы киляляр: кешегя кюремсез булыучы, жя ӱлем, бяля, чир теляӱче, кешене кыйнатырга, азаблатырга, ӱтерергя котортоучы, кешене кыйнаб, гареб итеӱче, аборт ясатыучы, аборт ясаучы, кешене жазыкка кертеӱче, Христос дененнян биздереӱче).*

**VII. Уйнашлык итмя** (*бу бойорого белян Алла азгынлык итяргя, жакынынңнын кадерен бетерергя, тормош буярга кушмый. Бу бойорокка карышы киляляр: жат ир (хатын) белян азгынлык итеӱче, узен шакшыландырыучы, кюңелдя уй белян уйнашлыу итеӱче, язылышмаган килеш «гражданский брак» белян тороучы*)

**VIII. Урлама.**

**IX. Жакыныңа карышы жалган таныклык итмя** (*бу бойорого белян Алла жакыныңа карышы жалганнаб, ант итяргя кушмый. Алла пагямбяре áйтя: «Телеңне жаманнан, ауызыңны алдаб сöйляӱдян тый», дей(Пс.33). Кешегя ничек итеб усаллык итсян, ӱзеңя дя шундый усаллык ителер).*

**X. Жакынынңнын хатыны булса, öйö булса, басыуы булса, ир коло булса, хатын коло булса, ӱгезе, ишяге, нейдей терлеге булса да, ич нястясеня кюңел салма, бу миңа булсын димя** *(бу бойорого белян Алла кеше нястясеня кюңел салырга кушмый, ӱзеңнекеңяр тук булырга куша).*

Шул бойорокларны халыкка Алла Моисей пагямбяр арткылы Синай тауында биргян. Бойороклар унау: ун бойорокнон дюртесе – Алланы сöяргя öйрятяляр, алтысы – жакыныңны сöяргя.

***Öй-хужалыгында кулланмаска***